КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 13 февраль г.Казань № 77

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификатлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуны оештыру һәм финанслар белән тәэмин итү турында» 2021 ел, 15 сентябрь, 872 нче карары белән расланган Өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификатлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуга бәйле чыгымнарны каплау максатларында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификатлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуны оештыру һәм финанслар белән тәэмин итү турында» 2021 ел, 15 сентябрь, 872 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 1 март, 189 нчы; 2023 ел, 28 ноябрь, 1524 нче; 2024 ел, 30 сентябрь, 844 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификатлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуга бәйле чыгымнарны каплау максатларында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга

Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү кагыйдәләренә, аларны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин